# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Юшады авыл җирлегенең Югары Юшады торак пунктында
2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**20.11.2023ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлегенең Югары Юшады авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлеге Югары Юшады торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2024 елда 1000 сум күләмендә үзсалым кертергә*1 һәм 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, тыл хезмәтчәннәре, күп балалы гаиләләр, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнар, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.*

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

-Югары Юшады торак пунктында Владимиров урамындагы торак пункт эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү).

3. Юшады авыл җирлегенең мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән, әлеге карарны Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://menselinsk.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Юшады авыл җирлеге башлыгы ____________ И.Р.Ханов
(имза)